Яна уку елы алдыннан «Педагог 13.ру» да республика педагогик форумы кысаларында Мордовия укытучылары «Педсовет-2026: белем бирv сыйфатын кvтәрvгә курс» топ диалог мәйданчыгында 2 секция эшләде.

Эшлекле программа vзәгендә- 2026/27 уку елында мәктәпләр эшенен гамәли аспектлары темасын Татьяна Васильевна Самсонова, «Педагог13.ру» vзәге ректоры ачты. Тагы 1 сентябрьдән vз кочено керә торган федераль белем бирv программаларындагы vзгәрешләрне жентеклэп тикшерделәр; белем бирv стратегияләрен гамәлгә ашыру очен нәшриятнын заманча кораллары һәм әзер карарлар тәкъдим иттелде; Мордовия мәктәпләрендә профильле һәм һонәри белем бирvне оештырунын унышлы кейслары белән дә уртаклаштылар. Секцияләр эшендә катнашучылар ГИА-2026 нәтижәләре турында фикер алыштылар, яна УМКлар һәм цифрлы ресурслар белән таныштылар. ЕГЭ һәм ОГЭ предмет комиссияләре рәисләре типик хаталарны профилактикалау буенча кинәшләр бирделәр.

Мордовия педагоглары һәм туган тел, әдәбият укытучылары очен «Мин туган тел һәм әдәбият дәресенә барам» методик практикумын «Этномәдәни белем бирv лабораториясе» модире Елена Михайловна Наумова житәкләде. Практикум кысаларында «Ел укытучысы» һәм «Ин яхшы туган тел укытучысы» конкурсларында жинvчеләр мастер-класслар уздырдылар. Алар арасында Мордовия республикасы Татар Пешлә урта мәк-тәбендә тырышып 40 ел дәвамында татар теле һәм татар әдәбияты буенча укучыларына ныклы белем бирvче Сания Спартак кызы Саляева мастер-класс бирде. Исегезгә тошерәбез: Сания Спартак кызы Саляева апрель аенда vткән Туган тел һәм әдәбият укытучыларынын Ботенроссия конкурсында «Укытучы - остаз (наставник)» номинациясендә жинv яулап кайтты.